**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы Карары**

22 сентябрь 2017 ел № 56

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталык һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләрне билгеләү максатларында, , Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен» 1 нче номерлы кушымта нигезендә расларга

2.2012 елның 11 маендагы 36 номерлы «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл башлыгы Р.Р.Хөснетдинов